**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4963**
**09.06.2023**

Башкарма комитетның «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасы турында» 2021 елның 2 августындагы 5091 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасы турында» 2021 елның 2 августындагы 5091 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче хәзерге һәм киләчәк буынның сәламәтлеген югары дәрәҗәгә җиткерү, шул исәптән халыкның үз сәламәтлегенә җаваплы мөнәсәбәтен формалаштыру, Яр Чаллы шәһәрендә сәламәт яшәү рәвеше алып бару, кеше потенциалын саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру максатында, Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгы тарафыннан паспорты расланган «Демография» илкүләм проектының «Иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» һәм «Сәламәт туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарның сәламәт яшәү рәвешен мотивацияләү системасын формалаштыру» федераль проектларына туры китереп, шәһәр Уставының 53 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә»;

2) «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Программаны эшләү өчен нигезләр» юлында «2015 елның 31 декабрендәге 683 номерлы» сүзләрен «2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 бүлектә беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгы тарафыннан паспорты расланган «Демография» илкүләм проектының «Иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» һәм «Сәламәт туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарның сәламәт яшәү рәвешен мотивацияләү системасын формалаштыру» федераль проектлары нигезендә, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче хәзерге һәм киләчәк буынның сәламәтлеген югары дәрәҗәгә җиткерү, шул исәптән халыкның үз сәламәтлегенә җаваплы мөнәсәбәтен формалаштыру, шәһәрдә сәламәт яшәү рәвеше алып бару, кеше потенциалын саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру максатында эшләнде.»;

- 4 бүлектә таблицаның 4 пунктында «2014 елның 25 декабрендәге 723 номерлы» сүзләрен «2022 елның 27 декабрендәге 985 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов